Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

12 март 2020 ел № 354

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының һәм район Башкарма комитеты җитәкчесенең 2019 елгы эшчәнлек нәтиҗәләре турында хисап

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы Россия Федерациясе Законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставы нигезендә, Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының һәм район Башкарма комитеты җитәкчесенең 2019 елгы эшчәнлек нәтиҗәләре турында хисабын карап фикер алышканнан соң, Әлмәт муниципаль районы Советы Башкарма комитет тарафыннан башкарылган эш нәтиҗәсендә районның социаль-икътисади үсеше өчен кирәкле шартлар булдыруын билгели.

Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә, Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының һәм район Башкарма комитеты җитәкчесенең 2019 елгы эшчәнлек нәтиҗәләре турында хисабын карап,

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының һәм район Башкарма комитеты җитәкчесенең 2019 елгы эшчәнлек нәтиҗәләре турында хисабын игътибарга алырга.

2. 2020 елга Башкарма комитетка беренче чираттагы бурычларны билгеләргә:

- федераль, республика программаларын гамәлгә ашыруны тәэмин итү;
- юл-урам челтәрен комплексны модернизацияләү чараларын үткәрү, алга таба җәмәгать урыннарын булдыру һәм төзекләндерү программаларын гамәлгә ашыру;
- квартал эчендәге территорияләрне комплекслы төзекләндерүгә юнәлдерелгән «Безнең ишегалды» республика программасының 1 нче этабын гамәлгә ашыру;
- торак-коммуналь хезмәтләргә түләү буенча бурычларны киметүгә юнәлдерелгән чаралар комплексын эшләү;
- аз катлы һәм күпфатирлы йортларның төзелеш темпларын арттыру өчен шартлар тудыру;
- Әлмәт онкология диспансерының радиология корпусы төзелешен тәгәлләү;
- районның су ресурсларын чистартуга юнәлдерелгән экологик чараларны гамәлгә ашыру; канализациянең чистарту корылмаларын реконструкцияләү эшләрен дәвам итү;
- шәһәр зиратларын һәм аларга якын территорияләрне карап тотуны һәм төзекләндерүне тәэмин итү;
- муниципаль маршрут буенча пассажирлар йөртүнең сыйфатын күтәрү, пассажир автотранспорты маршрутларын тикшерүнең гамәлдәге юлларын оптимальләштерү;
- муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең сыйфатын һәм һәркем файдалана алырлык булуын арттыруга юнәлдерелгән чараларны;сәламәтлек саклау, мәгариф

өлкәләрендә хезмәт күрсәтүләрнең сыйфатын күтәрүгә юнәлдерелгән чаралар комплексы гамәлгә ашыру;

- авыл җирлекләрендә яшәүчеләрне шәхси ярдәмче хуҗалыкларны һәм авылда кече эшкуарлыкны үстерү программаларында катнашуга җәлеп итү.

3. Район Башкарма комитетына Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елгы эшчәнлек нәтиҗәләре турындагы хисабын халыкка җиткерергә һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштыруны йөкләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны район Советының бюджет-финанс мәсьәләләре, җирле салымнар һәм җыемнар буенча даими комиссиясенә, социаль мәсьәләләр буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль район башлыгы Т.Д. Нагуманов